| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2016 г. Казань № под-2320/16

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр булдыру турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 600 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатында эш оештыру турында» 2016 елның 6 декабрендәге 2320 /16 номерлы боерыгы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр булдыру турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 600 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатында боерам:

1. Китерелгән формаларны расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты һәм студент арасында стипендияләр рәвешендә бирелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кайтару механизмын, якларның җаваплылыгын, шартнамәне үзгәртү һәм өзү тәртибен күзалдында тоткан укучы шартнамәсен;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты арасында Татарстан Республикасы бюджетыннан гайре бюджеттан тыш трансфертлар бирү турында шартнамә;

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен, башка бюджеттан тыш трансфертлар бирүгә гаризалар;

студент гаризасы.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Б. Алишевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры – министр Э.Н. Фәттахов

ТР Юстиция министрлыгында 2016 елның 23 декабрендә теркәлде
Теркәлү номеры 3765

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2016 елның 6 декабрендәге 2320/16
номерлы боерыгы белән расланган форма

Татарстан Республикасы _____________муниципаль районы (шәһәре)
Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмасында педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алучы студент арасында стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр турында
_________номерлы шартнамә

________________________ «___»__________ 20__ ел

Гамәлдәге устав нигезендә, бер яктан, Башкарма комитет җитәкчесе
_________________________________________________________________ йөзендә
(Башкарма комитет җитәкчесенең Ф.И.А.)
Татарстан Республикасының _________________муниципаль районы (шәһәре) Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет), һәм стипендия алучы (алга таба - Гражданин)
________________________________________________________________________,
(студентның Ф.И.А.)
икенче яктан, бергә Яклар дип атала, әлеге Шартнамәне имзаладылар, түбәндәгеләр хакында:

**1. Шартнамәнең предметы**

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр булдыру турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 600 номерлы карары

белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмасында педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алучы студент арасында стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләре кысаларында Яклар арасында килеп чыга һәм гамәлгә ашырыла торган мөнәсәбәтләр әлеге Шартнамәнең предметы булып тора (алга таба – Кагыйдәләр).

1.2. Әлеге Шартнамә нигезендә Гражданин көндезге уку формасы буенча гамәлгә ашырыла торган педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем хәзерләү юнәлеше буенча мәгариф программасын үзләштерергә, шулай ук күрсәтелгән мәгариф программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узарга һәм әлеге Шартнамә шартлары һәм 2.4.7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлек оешмасы белән хезмәт шартнамәсе (контракт) төзергә бурычлы, ә Башкарма комитет Гражданинга Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының __________ елның ___________ ____ номерлы боерыгы нигезендә стипендияләр рәвешендә ай саен акча түләргә бурычлы (алга таба – Нигезләмә).

## 2. Якларның бурычлары һәм хокуклары

2.1. Башкарма комитет хокуклы:

2.1.1. Гражданиннан әлеге Шартнамәнең барлык шартларын үтәүне таләп итәргә.

2.1.2. Гражданиннан уку планы нигезендә арадаш аттестацияләрне узу нәтиҗәләре һәм югары белем бирүче мәгариф оешмасы уставында һәм укучыларның эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган бурычларның үтәлеше турында мәгълүмат сорарга.

2.1.3. Гражданиннан әлеге Шартнамәнең 2.4.9 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны таләп итәргә.

2.1.5. Гражданин әлеге Шартнамәнең шартларын үтәмәгәндә, шулай ук Нигезләмәдә каралган очракларда стипендия бирү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга.

2.1.6. Гражданин әлеге Шартнамәнең 2.4.2, 2.4.4, 2.4.7, 2.4.7.1, 2.4.9 пунктларында каралган бурычларны үтәмәгән очракта, шулай ук 5.1.2, 5.1.3, 5.1.4, 5.1.5 пунктлар нигезендә, Гражданиннан стипендия түләүгә тотылган акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтаруны таләп итәргә.

2.2. Башкарма комитет бурычлы:

2.2.1. ел саен, 15 августка кадәр, Гражданинның уку елында башкарылган эше турында хисаплар, шулай ук югары белем бирүче мәгариф оешмасының хисап чорында Гражданинның эшчәнлеге турында бәяләмәсен (объектив сыйфатламасын) карарга.

2.2.2. Шартнамәне киләсе уку елына озайту яки Гражданин гаебе буенча, игътибарга алынмаслык сәбәп аркасында, Шартнамәне өзү турында карар кабул

итәргә.

2.2.3. Гражданин алган белгечлек нигезендә, муниципаль районда (шәһәр округында) булган вакансияләр турында мәгълүмат биреп, Гражданинга эшкә урнашуда ярдәм итәргә.

2.2.4. Гражданин әлеге Шартнамә шартларын бозган очракта, аны берьяклы тәртиптә гамәлдән чыгарырга.

2.3. Гражданин хокуклы:

2.3.1. Башкарма комитеттан әлеге Шартнамәнең барлык шартларын үтәүне таләп итәргә.

2.3.2. Шартнамәнең 5.3 пункты нигезендә берьяклы тәртиптә әлеге Шартнамәне гамәлдән чыгарырга.

2.3.4. белем алу эшчәнлегеннән аерылмыйча фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә.

2.3.5. алган белгечлек һәм квалификация нигезендә, Башкарма комитеттан эшкә урнашуда ярдәм сорарга.

2.4. Гражданин бурычлы:

2.4.1. әлеге Шартнамәнең һәм Кагыйдәләрнең шартларын үтәргә.

2.4.2. югары белем бирүче мәгариф оешмасында мәгариф программасы һәм уку планы нигезендә педагогик белем ____________________ буенча көндезге уку
(әзерлек юнәлеше коды)
формасын узарга.

2.4.3. ел саен агымдагы елның 1 августына кадәр үткән уку елының нәтиҗәләре буенча хисап һәм ирекле формада киләсе уку елына эшнең перспектив планын тапшырырга.

2.4.4. Башкарма комитетка әлеге Шартнамә шартларын, әлеге Шартнамә буенча бурычларны үтәүне кыенлаштыра торган гадәттән тыш хәлләр туу мизгеленнән алып, эш көннәре исәбеннән 20 көнлек срокта үтәп булмау турында, сәбәпләрен раслап күрсәтеп, вакытында хәбәр итәргә.

2.4.5. 5.1.3, 5.1.4, 5.1.5 пунктларда күрсәтелгән шартлар, шулай ук 2.4.2, 2.4.4, 2.4.7, 2.4.7.1, 2.4.9 пунктларда күрсәтелгән бурычлар үтәлмәү аркасында, әлеге Шартнамәне вакытыннан алда өзү очрагында, стипендия түләүгә тотылган акчаларны кайтарырга.

2.4.6. үзенең элемтә мәгълүматы (фамилиясе, яшәү адресы, телефон номеры һ.б.) үзгәргән очракта, эш көннәре исәбеннән 10 көнлек срокта бу хакта Башкарма комитетка язмача хәбәр итәргә.

2.4.7. югары белем бирүче мәгариф оешмасында укуны тәмамлаганнан соң, ике ай эчендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль (дәүләт) берәмлек оешмасы белән хезмәт шартнамәсе төзергә.

2.4.7.1. югары белем бирүче мәгариф оешмасында укуны тәмамлаганнан соң, ике ай эчендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль (дәүләт) берәмлек оешмасына хәзерлек юнәлеше (профиль) буенча эшкә урнашып, анда кимендә биш ел эшләргә.

2.4.8. әлеге Шартнамәнең 9 пунктында билгеләнгән гамәлдәге вакыты

чыкканчы, Эшкә алучы белән төзелгән хезмәт шартнамәсен гамәлдән чыгаруга сәбәп булган бернинди эш-гамәлләр кылмаска яки гамьсезлек күрсәтмәскә.

2.4.9. Башкарма комитетка хезмәт шартнамәсен өзү турында эштән китү көне алдыннан 1 эш көне эчендә хәбәр итәргә.

2.4.10. Гражданинга стипендияләр рәвешендә түләнгән акчаларны, түбәндәге очраклар булган көннән алып, ике ай эчендә кире кайтарырга:

Гражданин Татарстан Республикасы территориясендәге муниципаль берәмлек оешмасы белән Кагыйдәләрнең 17 пунктында билгеләнгән вакытта хезмәт шартнамәсен төземәгәндә;

Гражданин хезмәт шартнамәсен Кагыйдәләрнең 3 пункты өченче абзацында күрсәтелгән вакыттан алданрак өзсә;

әлеге Кагыйдәләрнең 13 пунктында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында, стипендия түләве туктатылган очракта.

## 3. Финанслау тәртибе

Әлеге Шартнамәне финанслауга бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр булдыру турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 660 номерлы карары нигезендә тормышка ашырыла.

## 4. Яклар җаваплылыгы

4.1. Яклар әлеге Шартнамә буенча бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, алар Россия Федерациясе законнары, әлеге Шартнамә һәм Кагыйдәләр нигезендә җаваплы була.

4.2. Гражданин әлеге Шартнамәнең 2.4.2, 2.4.4, 2.4.7, 2.4.7.1, 2.4.9 пунктларында каралган, шулай ук 5.1.2, 5.1.3, 5.1.4, 5.1.5 пунктлары нигезендә үз бурычларын башкармаган очракта, аңа стипендия рәвешендә түләнгән чыгымнарны, законда билгеләнгән тәртиптә, инфляцион чыгымнарны исәпкә алып, тулы күләмдә кайтарырга, шулай ук түләү вакыты узган очракта аның өчен аерым акча (неустойка) түләргә бурычлы.

Неустойка әлеге Шартнамәдәге бурычлар үтәлми калган һәр көн өчен өстәп исәпләнелә. Мондый неустойка күләме Гражданинга стипендия рәвешендә түләнгән акчаларның әлеге Шартнамәдәге бурычларны үтәү вакытын кичектергән һәр көн өчен 0,01 процентын тәшкил итә.

4.3. Җиңеп булмаслык көчләр нәтиҗәсендә килеп чыккан шартларда Яклар үз бурычларын тулы яки өлешчә үтәмәгән очракта җаваплы булмый.

## 5. Шартнамәне вакытыннан алда өзү нигезләре

5.1. Яклар тарафыннан әлеге Шартнамәне вакытыннан алда өзү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

5.1.1. Якларның әлеге Шартнамәнең шартларын үтәмәве.

5.1.2. Яклар тарафыннан алдан ялган мәгълүматлар тапшыру.

5.1.3. Югары белем бирүче мәгариф оешмасының уку елы азагында Гражданинның уку эшчәнлегенең нәтиҗәсезлеге.

5.1.4. Югары белем бирүче мәгариф оешмасының Гражданинның укуына һәм укудан тыш эшчәнлегенә канәгатьсезлек белдерелгән бәяләмәсе.

5.1.5. Гражданинны үз теләге белән мәгариф оешмасыннан азат итү.

5.2. Башкарма комитет теләге белән игътибарга лаек сәбәп буенча әлеге Шартанмәне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

5.2.1. Башкарма комитетның бетерелүе.

5.3. Гражданин теләге белән игътибарга лаек сәбәп буенча әлеге Шартнамәне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

5.3.1. Гражданинның педагогик хезмәт эшчәнлеген алып баруга комачаулый торган, тиешле документлар белән расланган авыруы.

5.3.2. Югары белем бирүче мәгариф оешмасында көндезге укуда белем алуга комачаулый торган, тиешле документлар белән расланган авыруы.

## 6. Шартнамәне үзгәртү һәм өзү тәртибе

6.1. Әлеге Шартнамә шартлары Яклар ризалыгы белән үзгәртелә ала.

6.2. Әлеге Шартнамәне гамәлдән чыгару яки туктатып тору өчен, моны теләгән Як икенче Якка, Шартнамәне өзү яки туктатып тору өчен нигезләрне раслаучы документлар беркетеп, язмача белдерү кәгазе юллый. Язмача белдерү кәгазенә җавап, бу документны алган көннән алып, 15 (унбиш) календарь көне дәвамында бирелергә тиеш.

6.3. Әлеге Шартнамәнең 5.2, 5.3 пунктлары нигезендә игътибарга лаек сәбәп аркасында әлеге Шартнамәне өзгән очракта, Гражданинга стипендия рәвешендә түләнгән акчалар кайтарылмый.

## 7. Форс-мажор

7.1. Әгәр бурычларны үтәмәү, әлеге Шартнамәне төзегәннән соң, Яклар алдан күрә яки булдырмый кала алмаган гадәттән тыш характердагы хәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан җиңелмәс көчләрнең шартлары нәтиҗәсе булган очракта, Яклар әлеге Шартнамә буенча бурычларны өлешчә яки тулысынча үтәүдән азат ителәләр.

Җиңеп булмаслык көчләр шартларына Яклар йогынты ясый алмаган һәм аларның килеп чыгышына җаваплылыкта булмаган вакыйгалар керә (җир тетрәү, янгын, инвалидлык алу, психик авыру, забастовкалар, дәүләт хакимияте

органнары карары яки боерыгы һ.б.).

7.2. Җиңеп булмаслык көчләр шартларына сылтаучы Як бурычлы:

7.2.1. Җиңеп булмаслык көчләр шартлары туган көннән алып, эш көннәре исәбеннән 20 көнлек срокта Якларга мондый хәлләр килеп чыгуы турында язмача формада хәбәр итәргә, өстәвенә, икенче Як таләбе буенча, дәүләт оешмасыннан алынган раслаучы документ бирелергә тиеш.

Мәгълүматта шартларның характеры, шулай ук Якларның әлеге Шартнамә буенча бурычларны үтәвенә һәм бурычларны үтәү срогына аларның йогынтысын (мөмкин булганча) бәяләү турында белешмә булырга тиеш.

7.2.2. Күрсәтелгән хәлләр тәмамланганнан соң, тиз арада бу хакта икенче Якка язмача хәбәр итәргә. Шул ук вакытта әлеге Шартнамә буенча бурычлар үтәүнең фаразланган вакыты күрсәтелергә тиеш. Әгәр хәбәр итү кәгазе җибәрелмәгән яки вакытында җибәрелмәгән булса, чыгымнар әлеге шартларда калган Як тарафыннан кайтарыла.

## 8. Каршылыкларны карау тәртибе

8.1. Әлеге Шартнамәдәге яки аңа бәйле рәвештә уртак фикергә килүче Яклар арасында туарга мөмкин барлык бәхәсләр һәм фикер каршылыклары сөйләшүләр юлы белән хәл ителергә тиеш.

8.2. Сөйләшүләр юлы белән килешүгә ирешү мөмкин булмаган очракта бәхәсләр суд тәртибендә карала.

8.3. Әлеге Шартнамә белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон нормалары кулланыла.

## 9. Шартнамәнең гамәлдәге вакыты

Әлеге Шартнамә аны Яклар имзалаган көннән алып, гамәлгә керә һәм аның буенча Яклар барлык бурычларын тулысынча үтәгәнче гамәлдә була.

## 10. Башка шартлар

10.1. Әлеге Шартнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Яклар тарафыннар үзара килешү буенча гына, әлеге Шартнамәдә һәм законнарда билгеләнгән шартларны үтәп, әлеге Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булачак өстәмә шартнамә төзү юлы белән кертелә ала.

10.2. әлеге Шартнамә рус телендә һәр Як өчен берәр данә бертигез юридикка көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

10.3. Яклар әлеге Шартнамәнең һәр пунктын игътибар белән өйрәнделәр, аңладылар һәм килештеләр, соңыннан мәҗбүр ителмичә, үз теләкләре белән аңа имза куйдылар.

## 11. Якларның адреслары, реквизитлары һәм имзалары

Татарстан Республикасы ___________________________муниципаль районы (шәһәре) Башкарма комитеты

Гражданин: ___________________________________
(Фамилия, исеме,атасының исеме)
__________________________
____________________________________
Туган көне: _____________________
Туу урыны: ____________________
Адрес: _____________________________
____________________________________
Паспорт: ___________________________
____________________________________
____________________________________

______________/____________________ ______________/_____________________
(Имза) (Имза)
«___»__________ 2016 ел «___»_____________ 2016 ел

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2016 елның 6 декабрендәге 2320/16
номерлы боерыгы белән расланган форма

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Татарстан Республикасының _____________муниципаль районы (шәһәре) арасында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмасында педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча белем алучы студент арасында стипендияләр рәвешендә айлык түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджеттан тыш трансфертлар бирү турында
_________ номерлы шартнамә

Казан шәһәре «___»___________ 2016 ел

Алга таба «Министрлык» дип аталучы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ______20__елгы _____ номерлы ышанычнамә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары _______________________________________________________________,
(Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Ф.И.А.)
йөзендә һәм алга таба «Алучы» дип йөртелүче Татарстан Республикасы ________________________________муниципаль районы (шәһәре) Башкарма комитеты, Устав нигезендә эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе_____________
_______________________________________________________________
(Башкарма комитет җитәкчесе Ф.И.А.)
йөзендә, алга таба «Яклар» дип аталучылар, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының ____ елга бюджеты турында» _______елгы _____

номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр булдыру турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 600 номерлы карары (алга таба – 660 номерлы карар), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ____елгы ____ номерлы боерыгы нигезендә әлеге Шартнамәне имзаладылар, түбәндәгеләр хакында:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Алучыга, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр өчен, ______ елда Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү әлеге Шартнамәнең предметы булып тора (алга таба – субсидияләр).

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр өчен, Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибенең 9 пункты нигезендә, Алучыга 660 номерлы карар, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының _____ елгы ___________ номерлы карары белән расланган бирелә торган субсидиянең күләме _______(___________________________) сум 00 тиен тәшкил итә.
(саннар белән) (сүз белән)

1.2. Субсидия Алучыга акчалар шәхси банк счетына______________________
______________________.
күчерү юлы белән тапшырыла.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Министрлык бурычлы:

2.1.1. Алучыга субсидияне әлеге Шартнамәдә булган шартларда __________ кадәрге вакыт эчендә күчерергә;

2.1.2. Шартнамәдән аңлашылган бурычларның үтәлешен контрольдә тотарга, шул исәптән,Алучының әлеге Шартнамә кысаларында алган субсидияне максатчан куллануын.

2.2. Министрлык хокуклы:

2.2.1. Алучының субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны үтәвен, һәм

тапшырылган хисапларның чынбарлыкка туры килүен тикшерергә;

2.2.2. Субсидия бирү максатларына һәм нәтиҗәлелегенә ирешүне бәяләргә;

2.3. Алучы бурычлы:

2.3.1. Әлеге Шартнамә буенча бирелә торган акчаларны әлеге Шартнамә предметында күрсәтелгән максатларда һәм билгеле бер тиешле чыгым маддәләре калькуляцияләре чикләрендә тотарга;

2.3.2. Әлеге Шартнамәдә каралганча, субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле кулланмаган, Министрлыкка ялган мәгълүмат биргән, мәгълүматны вакытында тапшырмаган очракта, әлеге Шартнамә нигезендә алынган акчаларны, Министрлыкның беренче язмача таләбе буенча, Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарырга;

2.3.3. Квартал саен (киләсе хисап кварталындагы айның 15енә кадәр) Министрлыкка, субсидияләрне чыгымнар маддәләре буенча аерып, тотылган акчаларның пландагы һәм фактик күләмен билгеләнгән закон тәртибендә күрсәтеп, куллану турында хисап тапшырырга;

2.3.4. Министрлык таләбе буенча, әлеге Шартнамә шартлары үтәлешен тикшерү уздыру өчен, мәгълүмат һәм документлар бирергә;

2.3.5. Агымдагы финанс елының 31 декабренә кулланылмаган субсидияләрнең өлеше Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш;

2.3.6. Тиешле шартлар туган мизгелдән алып, 5 (биш) эш көне эчендә субсидиягә ихтыяҗ бетүе турында Министрлыкка язмача хәбәр итәргә;

2.3.7. Түләү реквизитлары үзгәргән очракта, тиз арада вәкаләтле зат имзалаган тиешле язмача белдерү кәгазе юллау юлы белән Министрлыкка хәбәр итәргә;

2.3.8. Алучыны бетерү турында карар кабул ителгән очракта, бу хакта әлеге карар кабул ителү мизгеленнән алып, өч көн эчендә Министрлыкка хәбәр итәргә;

2.3.9. Субсидиянең күләме үзгәрүгә йогынты ясый торган шартлар турында Министрлыкка вакытында хәбәр итәргә;

2.3.10. Шартнамә үтәлешен тоткарлаучы барлык шартлар турында тиз арада Министрлыкка хәбәр итәргә;

2.3.11. Министрлыкка һәм дәүләт финанс контроле органнарына Алучы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибе үтәлешен тикшерергә тоткарлык ясамаска.

2.3.12. Әлеге Шартнамә буенча бурычларны үтәү барышында алынган конфиденциаль мәгълүматны башка затларга бирмәскә, башка ысул белән таратмаска.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге Шартнамә буенча үз бурычларын үтәмәгән яки нәтиҗәсез үтәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

3.2. Алучы, субсидияләрне максатчан, нәтиҗәле кулланмаган, әлеге Шартнамәдә билгеләнгән субсидияләрне бирү максатлары нигезендә, аны бирү һәм куллану шартларын үтәмәгән, әлеге Шартнамәдә каралганча, Министрлыкка

мәгълүматның вакытында бирелмәве һәм аның ялган булганы өчен, Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплы була.

3.3. Субсидияне максатсыз һәм нәтиҗәсез кулланган, Министрлыкка ялган мәгълүмат биргән, әлеге Шартнамәдә каралганча, мәгълүматны вакытында тапшырмаган очракта, тиешле акчалар, алга таба тиешле законнарда билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджетына тапшыру өчен, Министрлык тарафыннан кире алына.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Яклар арасында бәхәсләр сөйләшүләр юлы белән хәл ителә, килешүгә ирешмәгән очракта – Татарстан Республикасының Арбитраж судында.

4.2. Әлеге Шартнамә Яклар теләге буенча әлеге Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булган аңа өстәлмәләр рәвешендә язмача формада үзгәртелә.

4.3. Әлеге Шартнамә Якларның үзара килешүе яки икенче Як тарафыннан әлеге Шартнамә шартларын бозган очракта якларның берсе таләп иткәнчә, һәм әлеге Шартнамәнең гамәлдән чыгарылу сәбәпләрен күрсәтеп, гамәлдән чыгару турында язмача белдерү кәгазе тапшырган очракта гамәлдән чыгарыла ала.

4.4. Шартнамә аны Яклар имзалаган көннән алып үз көченә керә һәм Яклар бурычларын тулысынча үтәгәнче гамәлдә була.

4.5. Әлеге Шартнамә өч нөсхәдә төзелде. Алар бертигез юридик көчкә ия, ике нөсхә – Министрлыкка, берсе – Алучыга.

## 5. Якларның түләү реквизитлары

Татарстан Республикасы __________________________ муниципаль районы (шәһәре) Башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Юридик адрес: 420111, ТР, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт
Фактик адрес: 420111, ТР, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт

Банк реквизитлары:
ИНН 1654002248
Татарстан Республикасы буенча УФК (ТР ФМ
л\с 02092011000
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
л\с ЛБ007080001)
р/с 40201810900000000002
БИК 049205001
КПП 165501001
ОКАТО 92401367000

ОКОПФ 72
ОКПО 00099837
ОКВЭД 75.11.21
Керем администраторы коды: 708

ТР мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары

______________/________________ ____________/_________________
Имза                                                    имза
М.У.                                                    М.У.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2016 елның 6 декабрендәге 2320/16
боерыгы белән расланган форма

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы мәгариф һәм
фән министры
____________________ (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(юридик затның ИНН)   (юридик затның урыны)
___________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру максатында,

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге атамасы)
башка бюджетара трансфертлар бирүегезне үтенәм.
Форма буенча юридик затның вәкиле турында мәгълүмат:

| Оешма җитәкчесенең Фамилиясе, Исеме, Атасының исеме | Элемтә өчен телефон, факс, e-mail |
|---|---|
| | |

**Нигезләмәләр:** ТР Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 сентябрендәге 660 номерлы карары белән раслаган Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына педагогик эшчәнлек төрен күзалдында тоткан югары белем бирүче мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибенең 5 пункты нигезендә

Гариза тапшыру датасы
Юридик зат җитәкчесенең имзасы
Мөһер урыны (булган очракта)

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 6 декабрендәге 2320/16 номерлы боерыгы белән расланган форма

Татарстан Республикасы ____________________
муниципаль районы (шәһәре) Башкарма
комитеты җитәкчесе _________________________
________________________________________
(җитәкченең Ф.И.А.)
____________________________________________
(институт/факультет исеме)
______ курсының _____ төркеме студенты
________________________________________

________________________________________
(тулы Ф.И.О.)
Паспорт: N |_|_|_|_| |_|_|_|_|_|_|

бирелгән «___»_______________ 20|_|_| ел

________________________________________
(кем биргән)
ИНН: |_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|

________________________________________
(индекс, теркәлү адресы)
________________________________________
(телефон номеры, электрон почта адресы)

**Студент гаризасы**

Миңа Сездән _______________________________________________________________
(Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү оешмасы исеме)

педагогик эшчәнлек төрен күзалдында торткан югары белем бирү хәзерлеге юнәлеше буенча көндезге бүлектә белем алу дәверендә 15,0 (унбиш) мең сум күләмендә стипендия рәвешендә айлык түләү бирүегезне үтенәм.
Китерәм: 1. Урта белем алу турында аттестатның ____ битлек 1 данә күчермәсе;
2. Физик затның яшәү урыны буенча салым органында исәпкә алыну турында таныклыкның ____ битлек 1 данә күчермәсе;
3. Паспортның ____ битлек 1 данә нөсхәсе;
4. Студентның республика, Бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәләрдәге олимпиадаларда катнашуын раслый торган, өч ел эчендә алынган, югары белем бирү мәгариф оешмасына укырга керүенә китергән грамоталар һәм дипломнарның _____ битлек 1 данә күчермәләре (булган очракта);
5. Исәп-хисап счеты һәм банк картасы номеры турында ____ битлек 1 данә мәгълүмат;

6. ____ битлек 1 данә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

_________________/____________________
(Имза/ Ф.И.А.)
Гариза тапшыру датасы